СОВЕТ
УЛЬЯНКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
УЛЬЯНКОВО АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ

КАРАР

15.12.2022 Ульянково ав. №62

Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Советының кайбер карарларын юкка чыгару турында

«Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын, муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләрне тапшыру тәртибе турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм муниципаль норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Советының:

2016 елның 08 апрелендәге 27 номерлы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында»;

2022 елның 14 июлендәге 51 номерлы «Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлегенең керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү турында аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» карарларын юкка чыгарырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында https://pravo.tatarstan.ru, авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Ульянково авыл җирлеге Башлыгы, Совет рәисе Ф.А.Сундурова